# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

***Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы*** *№6 Апрель 2023 ел*

**Ватанны яратырга, Кеше булырга, бергә булырга, хәрәкәттә булырга, беренче булырга. «Алдынгылар хәрәкәте» республика күләм форумында шушы турыда сөйләштеләр**

«Алдынгылар хәрәкәте» бөтенроссия балалар һәм яшьләр хәрәкәте Россия Президенты Владимир Путин карары нигезендә узган ел оешты. Яңа хәрәкәт бөтен ил яшьләрен бер йодрыкка тупларга тиеш. Татарстанда бу эшне зур ышаныч белән Татарстан Президенты ярдәмчесе Тимур Сөләймановка тапшырдылар.

– Хәрәкәт эшендә балалар һәм яшьләр турыдан-туры катнашачак. Алар кечкенәдән үк үзләрен бу хәрәкәтнең бер өлеше итеп тоярга тиеш, – диде «Алдынгылар хәрәкәте»нең Татарстандагы төбәк бүлеге советы рәисе Тимур Сөләйманов. – Әлеге хәрәкәт киң катлау балалар һәм яшьләрне берләштерәчәк. Монда аларның һәркайсы күңеленә хуш килгән, кызыклы һәм мавыктыргыч шөгыль табарга тиеш.

Берәү дә читтә калырга тиеш түгел. Республиканың һәр районында иҗтимагый штаблар, ә мәктәпләрдә, махсус клублар оештырылачак.

Без дә бу хәрәкәткә кушылдык. Районыбыздан форумга барган укучылар арасында безнең мәктәптәннән 7-8 класс укучылары катнашты. Форум безгә ошады. Барлык мероприятие һәм очрашулар кызыклы итеп узды. Без бик күп яңа дуслар таптык. Яңа максатлар билгеләдек, яңалыклар белдек.

Татарстанда «Алдынгылар хәрәкәте» 13 юнәлештә эшләячәк. Алар – мәгариф, фән, хезмәт һәм һөнәр, мәдәният һәм сәнгать, ирекчелләр, ватанпәрвәрлек, спорт, сәламәт яшәү рәвеше, медиа, дипломатия һәм халыкара мөнәсәбәтләр, экология, туризм, туган тел, милли мәдәният һәм традицияләр. Һәркем өчен мөмкинлекләр ачыла. Әйдәгез, безнең белән! Алдынгылар белән алга!

Камаева Ләйлә, Ганиева Дилә, Калимуллина Гөлия ,
8 сыйныф укучылары

## Интернет-диета

Дөньяда бик күп диеталар бар. Әмма минем диета берәүдә дә юк.

Шулай бер көнне әни әйтеп куймасынмы:

- Улым, көне-төне интернетта утырасың. Мин сиңа интернет-диета игълан итәм. Бүгеннән интернетта көнгә 15 минут кына утырасың!
- Унбиш минут!!! Бу бит кризис! – дип уйладым мин. Ләкин мин ситуацияне дөрес бәяләмәгән булып чыктым. Интернет-диета бик шәп шәрсә икән! Хәзер минем китап укырга да, урамда уйнарга да, әнигә булышырга да вакыт бар! Яшәсен интернет-диета!

Батталов Аяз, 2 нче сыйныф



**Апрель аенда хөрмәтле укытучыбыз Рәйсә Равил кызының, оператор Мансур улының туган көннәрә. Аларга зур уңышлар, сәламәтлек, бәхетле, тигез, тыныч тормыш телибез!**

## “Куркынычсыз тәгәрмәч”



Без, 4 сыйныф укучылары, 24 апрель көнне район күләм “Куркынычсыз тәгәрмәч” конкурсында катнаштык.Әлеге чарада юл йөрү кагыйдәләре буенча белемнәребезне, көчебезне сынадык. Бу чараны без түземсезләнеп көттек.Юл йөрү кагыйдәләрен көн дә белү кирәк. Без көн саен машина юлы аркылы чыгабыз, автобуста хәрәкәт итәбез, әти-әниләребез машинасында пассажирлар булып, көн дә укырга киләбез. Юлларда велосипед белән хәрәкәт итәбез. Шуна да безгә юл йөрү кагыйдәләрен белү кирәк. Без төрле сынауларны үттек. ”Иҗади танышу”, ”Медициина буенча белемнәрне тикшерү” , “Юл йөрү кагыйдәләре буенча тест”, “Велосипедны фигуралы йөрү” номинацияләрендә катнаштык. Конкурста актив катнашкан өчен бик күп бүләкләргә дә ия булдык.

Фазуллин Раяз, 4 сыйныф

## Оя ясадым!

Бозлар киткән, язлар житкән
Бик күп кошлар килгәннәр,
Минем оя ясаганны
Әллә инде күргәннәр.
Бик тырышып эшләдек шул
Әти белән бергәләп,
Бармакка да сугып алдым
Әни йөрде көлгәләп.

Гилязов Ранис, 6 сыйныф

## Хыял

Әгәр кеше хыяллана белмәсә, җәмгыять бер урында гына торыр иде. Хыялларны тормышка ашыру юлында кешеләр зур ачышлар ясаганнар, тормышны, яшәешне үзгәрткәннәр. Минемчә, хыял буш җирлектә генә туарга тиеш түгел. Хыял тормышчан булганда гына чынга аша. Мәсәлән, кечерәк чакта мин үземдә булмаган уенчыкларны булдыру турында хыяллана идем. Зуррак үскәч, укый белә башлагач, китаплар, төрле матур киемнәр турында да хыялландым. Бу хыялларымны тормышка ашыру миннән тормый иде, әлбәттә. Ә хәзер мин яхшы укырга, бик белемле булырга һәм үзем теләгән уку йортына керү турында уйланам. Бу күп тырышлык, нык ихтыяр көче таләп итсә дә, аның тормышка ашуы үземнән тора. Бөтен көчемне куеп тырышсам, хыялларым чынга ашар дип өметләнәм. Минә шул тормышчан хыялны чынга ашыру бездән күп сыйфатлар таләп итә. Болар һәркемдә була ала торган тырышлык, уңганлык, нык ихтыяр көченә ия булу, тормышны ярату, тирә-юньдәгеләргә игътибарлы булу, мәрхәмәтлелек, үз-үзенә дөрес бәя бирә белү, житешсезлекләреңнән арынырга тырышу, зыялы булырга омтылу, тырышып уку, бөек кешеләрдән үрнәк алу һәм башка бик күп сыйфатлар. Бу сыйфатларга һәркем ия була ала. Димәк, хыялга бары бер адым гына ясарга кирәк.

Гатауллина Зәринә, 11 сыйныф

## Рәхмәт Сезгә укытучым!!!



Мәктәпне тәмамаларга бер ел гына вакыт калып бара. Классыбыздагы бар укучы да, киләчәктә белем алуны дәвам итүне Казанда яки Мәскәүдә дип күз алдына китерә. Башкаланы күбрәк өйрәнү максатыннан сыйныф җитәкчебез белән без Казанга юл тоттык. Шәһәр безне бик җылы каршы алды. Көн дәвамында истәлекле урыннарда йөреп, үзебез күрергә теләгән матур урыннарны карап рәхәтләнеп бәйрәм иттек. Шундый искиткеч ял оештырганы өчен сыйныф җитәкчебезгә зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Форсаттан файдаланып мәктәбебезнең барлык укытучыларына да авыр һәм җаваплы эшләрендә уңышлар телибез.

10 сыйныф укучылары

## Җиденчеләр гел алга -уңышлар юуларга!



Классыбыз “Ажаган”да катнаша.

Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы белән очрашу



Форум “Алга!Поехали!”



## Китапханәдә кунакта



11 апрель көнне без 1нче сыйныф укучылары авыл китапханәсенә кунакка бардык. Безне китапханә мөдире Вафина Луиза апа бик җылы каршы алды.Ул 12 апрель – Космонавтика көне турында сөйләде. Планеталар турына презентация күрсәтте. Без Луиза апа сөйләгәнен бик кызыксынып тыңладык. Биргән сорауларына бик төгәл җавап бирдек. Аннан тосле кәгазьдән ракеталар ясадык. Соңыннан Луиза апа китапханә белән таныштырды. Без үзебез теләгән әдәби китапларны сайлап алдык. Китапханә бик ошады, киләчәктә тагын барырга сүз бирдек.

Брча Амира, 1 сыйныф



Безнең Зәринәбез Татар теленнән Халыкара олимпиада да уңышлы чыгыш ясап , диплом белән бүләкләнде. Киләчәктә дә гел уңышлар юлдаш булсын!

## Бабам белән горурланам!

Минем карт бабам -Сибгатуллин Мәулит Сибгатулла улы нык һәм көчле рухлы кеше булган. Ул 1911 елда Теләче районы Балыклы авылында туган.Кечкенәдән күп михнәтләр күргән,этисен яшьтән юлбасарлар хөҗүм итеп үтергәннәр,аннан йортлары янып беткән.
Минем бабам бик тырыш, уңган, оста итекче, гармунчы, җырчы булган.Ләкин 1941 нче елда сугыш башлану сәбәпле, минем бабам да сугышка китә, күп батырлыклар кыла, ләкин ул әсирлеккә төшә.Бабаем төшенкелеккә бирелми,башка әсирләргә ярдәм итә, чит телләр белү сәбәпле аларга ашарга ризык та табыша.Ул әсирлектән кача.Немецларга каршы сугышуын дәвам итә.Җиңү яулап, туган якларга кайта.Анын кайтуын әбием Мәрьям ике кечкенә баласы белән сагынып көтеп ала.Бабам кайткач, гаиләләре тагын да ишәя.Кызганычка каршы бабамның сугышта алган яралары озак яшәргә комачау итә, 1984 нче елның 22 нче сентябрендә ул вафат була..

Хадиева Иделия, 3 сыйныф

## Туган җирем- бер генә!

Туган ягым, туган авылым,
Мин – синең газиз балаң.
Саф сулы чишмәләреңнән
Җаныма сихәт алам.
Сусавымны басар кебек
Туган як чишмәләре.
Җилләрнең дә иң назлысы
Шул яктан искәннәре.

Чишмәләр, туган як чишмәләре... Бик якын да, бик файдалы да, безнең тарих та алар. Безнең йортыбызга капма –каршы челтерәп чишмә ага. Аны - Гарәфи чишмәсе дип атыйлар. Чөнки ул чишмәне файдаланырлык дәрәҗә китергән кеше- нәкъ менә күршебез Гарәфи абый. Ул инде бу дөньяда юк, ләкин кешеләр өчен иң кирәкле чишмә әле дә ага. Анын суы чиста, саф һәм бик тәмле. Без гаиләбез белән тәмле чәйләрне шул чишмә суы белән эчәбез. Чишмәләрне сакларга кирәк, алар бик файдалы һәм алар безнең үткән тарихыбыз. Халкыбызның сакланып калган ядкаре.

Халитова Илвинә, 5 сыйныф

## Без инде зурлар!



Бүгенге көн белем бирү системасы заман белән бергә атлый. Җәмгыятькә иҗади фикерли белүче, аралашучан, талантлы кешеләр сорала. Шушы максатларны күздә тотып безнең беренче сыйныф укычылары үзләренең эшләгән проектларын якладылар. Бу эшне, беренче тапкыр гына эшләүләренә карамастан, алар бик тырыштылар, үзләренең осталыкларын күрсәттеләр. Киләчәктә дә аларга уңышлар юлдаш булсын!

Сыйныф җитәкчесе Ганиева Л.

## **Халык сынамышлары**

Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коры була.
Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласа, яз тиз килә.
Кара карга килгәч, бер айдан кар кар китәр.
Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.
Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.
Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.
Язын иртә күк күкрәсә, ел янгырлы булыр.
Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.

**Яңалыклар**

- 75 ел элек «Алтынчәч» операсы өчен (Муса Җәлил либреттосы) композитор Нәҗип Җиһановка СССРның Дәүләт премиясе бирелә (1948)
- 140 ел элек Бакчасарай шәһәрендә төрки-татар телендә «Тәрҗеман» газетасы нәшер ителә башлый (1883–1918)
- 110 ел элек Казанда татар телендә рәсемле балалар журналы «Ак юл» чыга башлый (1913–22.01.1916)
- Шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Мәхмүт Хафиз улы Хөсәеннең (Хөсәеновның) тууына 100 ел
- Язучы-прозаик, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, профессор, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ибраһим Зиннәт улы Нуруллинның тууына 100 ел (1923–1995)